КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2024 ел, 13 март г.Казань № 138

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасының Сәнәгать һәм сәүдә министрлыгы каршындагы нефть сәнәгате объектларында сәнәгать иминлеге һәм гадәттән тыш хәлләрне кисәтү өлкәсендә җитештерү эшчәнлеге һәм законнарны камилләштерү мәсьәләләре буенча техник совет турында» 2018 ел, 24 гыйнвар, 36 нчы карарына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасының Сәнәгать һәм сәүдә министрлыгы каршындагы нефть сәнәгате объектларында сәнәгать иминлеге һәм гадәттән тыш хәлләрне кисәтү өлкәсендә җитештерү эшчәнлеге һәм законнарны камилләштерү мәсьәләләре буенча техник совет турында» 2018 ел, 24 гыйнвар, 36 нчы карарына (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2019 ел, 16 апрель, 302 нче, 2020 ел, 2 май, 359 нчы, 2023 ел, 9 февраль, 117 нче, 2023 ел, 4 апрель, 407 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

әлеге карар белән расланган Татарстан Республикасының Сәнәгать һәм сәүдә министрлыгы каршындагы нефть сәнәгате объектларында сәнәгать иминлеге һәм гадәттән тыш хәлләрне кисәтү өлкәсендә җитештерү эшчәнлеге һәм законнарны камилләштерү мәсьәләләре буенча техник совет турындагы нигезләмәдә:

2 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2. Татарстан Республикасының Сәнәгать һәм сәүдә министрлыгы каршындагы нефть сәнәгате объектларында сәнәгать иминлеге һәм гадәттән тыш хәлләрне кисәтү өлкәсендә җитештерү эшчәнлеге һәм законнарны камилләштерү мәсьәләләре буенча техник совет (алга таба - Техник совет) даими эшләүче консультатив-киңәшмә орган булып тора һәм сәнәгать иминлеге өлкәсендә кирәгеннән артык административ киртәләрне бетерү һәм гадәттән тыш хәлләрне кисәтү, нефть сәнәгате объектларында

әйләнә-тирә мохитне саклауны тәэмин итү һәм, күрсәтелгән өлкәләрдә куркынычсызлыкны арттыру максатыннан, норматив хокукый җайга салуны камилләштерү буенча килештерелгән карарлар әзерләү эшләрен алып бару өчен төзелә.»;

4 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«4. Техник советның төп бурычлары:

4.1. Нефть компанияләре эшчәнлеге процессында барлыкка килә торган гадәттән тыш хәлләрне кисәтү, табигатьтән файдалану, әйләнә-тирә мохитне саклау өлкәсендәге проблемалы мәсьәләләрне, тискәре техноген йогынтыны чикләү, калдыклар белән эш итү һәм дәүләт экология экспертизасын узу һәм аларны хәл итү буенча килештерелгән тәкъдимнәр әзерләүне карау.

4.2. Нефть компанияләре эшчәнлеге процессында барлыкка килә торган сәнәгать куркынычсызлыгы өлкәсендәге проблемалы мәсьәләләрне карау һәм аларны хәл итү буенча килештерелгән тәкъдимнәр әзерләү.

4.3. Федераль законнарны һәм Татарстан Республикасы законнарын камилләштерү максатларында әлеге пунктның 4.1 һәм 4.2 пунктчаларында күрсәтелгән өлкәләрдә барлыкка килә торган проблемалы мәсьәләләр буенча тәкъдимнәр һәм килештерелгән тәкъдимнәр әзерләү.»;

6 пунктның икенче абзацында «дәүләт хакимияте башкарма органнары» сүзләрен «республика башкарма хакимият органнары» сүзләренә алмаштырырга;

әлеге карар белән расланган Татарстан Республикасының Сәнәгать һәм сәүдә министрлыгы каршындагы нефть сәнәгате объектларында сәнәгать иминлеге һәм гадәттән тыш хәлләрне кисәтү өлкәсендә җитештерү эшчәнлеге һәм законнарны камилләштерү мәсьәләләре буенча Техник совет составында:

Техник совет составыннан Р.Р.Гыйсмәтовны, А.А.Запорожченконы, Л.А.Кәбировны, М.Ф.Минибаевны, С.Г. Пичугинны чыгарырга;

Техник совет составына кертергә:

| | |
|---|---|
| Гуськов Дмитрий Владимировичны | Татарстан Республикасы сәнәгать һәм сәүдә министры урынбасарын, Техник совет рәисе урынбасарын |
| Гобәйдуллин Илнур Ирек улын | Татарстан Республикасы экология һәм табигый байлыклар министрының беренче урынбасарын – әйләнә-тирә мохитне саклау өлкәсендә Татарстан Республикасы баш дәүләт инспекторын |
| Шакиров Фаяз Фәнил улы | Табигатьтән файдалану өлкәсендә күзәтчелек итү федераль хезмәтенең Идел-Кама төбәкара идарәсе җитәкчесе (килешү буенча). |

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин